
Хәсән Туфан



ХУШ КИЛӘСЕЗ Х.ТУФАН ТУГАН-
ИСКЕ КӘРМӘТ АВЫЛЫНА
Әйе,Кармәт авылына килеп керүгә таң
каласың. Шагыйрьнең яраткан чишмәсе
мөлдерәп тулып, каеннары гөрләп үсеп утыра.!



Иң беренче эш итеп без туп-туры Мафирә апа белән Гаяз абый Минҗәләевларга юл тоттык.


1905 елда Хәсәнша мулла Ахмеров һәм
Х.Туфанның әтисе  төзеткән мәчет
1995 ел



Намаз укыр өчен мәчеткә кермәкче идек,ләкин халык йөрмәү сәбәпле мәчет ачылмады.

Хәсән Туфан рухына дога колып мәчеттән чыгып киттек



Юлда безгә беренче очраган кеше Галина апа.




Менә музейга да килеп җиттек



Музей каршында ике куш каен үсеп утыра.



Раушания апа Миннеханова борчылып арлы-бирле йортта йөри иде.Капканы ачып керүгә уң якта матур итеп кара җирдән ромашка чәчәге ясалган,аның таҗларына төрледән-төрле чәчәкләр утыртылган.Көз булуга карамастан алар гөрләп үсеп утыра.




Музейда ике зал

Беренче зал Кармәт авылы тарихына багышлана.







Авылда татарлар,руслар,чувашлар яши.



# Хәсән абыйның бала чагы




Хәсән Туфан абыйның мәдрәсәдә
укыган вакыты

# 2 нче зал



9елга сузылган  дуслыктан соң Луиза апа белән өйләнешәләр.Бик матур гына яши башлыйлар,кызлары Гөлкәй туа.





Хәсән Туфан абыйның Урал да булган вакыты

Музейның иң түрендә өстәл һәм урындык,урындык артында яшел күлмәк Бу күлмәк 16 ел әрнегән күңелдән саркып чыккан канлы яшь аралаш тукылган  .



Музейдагы һәрбер нәрсәне күзәттем.Туфан абый шулхәтле тыйнак булган, хәтта аның ашаган-эчкән савытлары да кеп-кечкенә.Аның пальтосы,сәгате...








"Хәсән абый лагерьдә чакта да кешелек сыйфатларын югалтмый.Үзе башкалар кебек ачлыктан интексә дә иптәшләре белән соңгы ипиен бүлешә.



КАЗАНЬ.

Въ пятницу, 1-го марта (н. с.) 1918 г. въ 3 ч. дня
НА ТЕАТРАЛЬНОЙ ПЛОЩАДИ
ИМѢЕТЪ БЫТЬ

ТОРЖЕСТВЕННОЕ ПРОВОЗГЛАШЕНІЕ
ФЕРМАНА (Универсала)
ОБЪЯВЛЕНІЯ АВТОНОМІИ
ИДЭЛЬ-УРАЛЬСКОЙ
РЕСПУБЛИКИ

...акъ федеративной части Россійской Совѣтской
Рабоче-крестьянской республики.

...ЖДАНЕ—русскіе, чуваши, черемисы, евреи и др. народы! На нашемъ
...ени написано братство народовъ—въ этотъ историческій день подайте
намъ братскую руку.

ГРАЖДАНЕ! Ознаменуйте этотъ историческій день.

...Мус. Воен. Съѣздъ, Коллегія по осуществленію республики и всѣ демокр. мус. организаціи
стоящія на платформѣ Совѣтовъ.






М. Җәлил автографы
Автограф М. Джалиля

Аның күңелендә бернәрсә үзгәрешсез калган туган халкына,теленә булган керсез мәхәббәт.Бу мәхәббәтне ул Сталин лагерьлары аша да  саклап алып кайта, торгынлык елларының рәхимсез милли сәясәте басымы астында да югалтмый.





1970 елда Хәсән Туфан абый авылына кайта. Авыл халкы бик сөенә,кич белән халык мәдәният йортына агыла.Анда алар аның сүзләренә иҗат ителгән җырлар җырлыйлар,шигырьләрен сөйлиләр чын күңелдән аны яратып сөйләшәләр.




Хәсән туфан абыйның
каләмдәшләре белән очрашуы.




Илдар Юзеев иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичәсендә
3.4.64. г. Тукай клубында.

Аннан соң юлны без мәктәпкә тоттык
Мәктәптә безне ягымлы йөз белән каршы алдылар



Укучыларда Хәсән Туфан идеялары белән яшиләр.





- Мин баш иям Туфан,
- Синдәгедәй
- Тугрылыкка,талант һәм моңга,
- Мөстәкыйльлек алды
- Сөйгән халкың,
- Син яшәрсең туган халкыңда!

# МУЗЕЙДАН МИН РУХИ ЯКТАН БАЕП,КҮҢЕЛКӘЙЛӘРЕМ ТУЛЫП, ТАШЫП КАЙТТЫМ.

- "Йөрим таңда Кармәт авылында"
- Йөрим таңда Кармәт авылында
- Күңелем Туфан белән сөйләшә.
- Юл буенда үскән үләннәр дә,
- Нәкъ Туфанча итеп эндәшә.
- Йөрим таңда Кармәт авылында
- Шушы авыл,шушы түгелме соң?!
- Саклау өчен җанын көрәшкән.

- Каен,усакларың сине
- Нахаклардан яклап саташкан,
- Шушы авыл,шушы түгелме соң.
- Агыла да болыт агыла,
- Еракларга китеп сарыла.
- Кармәт каеннары,таллары да
- Сагынадыр сине,сагына.
- Агыла да болыт агыла.